| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.07.2023 ел Баулы шәһәре №157

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 120 номерлы “Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру турында тәмамлау актын рәсмиләштерү хакында” карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законына ярашлы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 120 номерлы “Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру турында тәмамлау актын рәсмиләштерү хакында” карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

преамбулада “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ

регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” сүзләрен алып ташларга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

2 бүлектә “Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары”

2.4.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты - күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру турында гариза бирелгән көннән алып 45 көннән артмаска тиеш (алга таба - гариза). Гариза бирүче документларны күп функцияле үзәк аша тапшырган очракта, килештерү яки килештерүдән баш тарту турында карар кабул итү вакыты күп функцияле үзәк тарафыннан мондый документларны тапшырган көннән исәпләнә.

Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул итүне яки баш тарту турында карар кабул итүне раслаучы документ бирү вакыты - мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне.»;

3 нче бүлектә " административ процедураларны үтәүнең составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буенча, гомуми билгеләр белән берләшкән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү тәртибен үз эченә ала»:

3.8. һәм 3.9. пунктлары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«3.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү очраклары һәм тәртибе алдан (проактив) режимда
Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү каралмаган.

3.9. Гомуми билгеләр белән берләштерелгән, мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә муниципаль хезмәт күрсәтү, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәләренә карата да

Муниципаль хезмәт мөрәҗәгать итүченең категориясенә һәм мөрәҗәгать итү нигезенә карамастан күрсәтелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе вазифаларын башкаручы И.И. Хөснуллина